| | |
|---|---|
| УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

07.06.2024 Казан ш. № 01-05/156-пр

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 2022 елның 28 июлендәге 01-05/187-пр номерлы боерыгы белән расланган Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карап тикшерү комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүне камилләштерү һәм элек чыгарылган норматив актларны федераль законнар таләпләренә туры китерү максатларында,

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 2022 елның 28 июлендәге 01-05/187-пр номерлы боерыгы белән расланган Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карап тикшерү комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

2 бүлектә:

2.9 пунктның икенче кызыл юлын түбәндәгечә үзгәртеп бирергә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җыем Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.11.2023 ел, № 373-5/нпс-2023 карары белән билгеләнгән күләмдә алына һәм Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе сайтында урнаштырылган.»;

2.9 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә хезмәт күрсәткән өчен җыем күләме 350 сум тәшкил итә.».

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче А.Ш. Борһанов